


2025 елнын 8 октябрендә республикабызнын матбугат Үзәгендә Мордовия Республикасы хәрби комиссары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы подполковник Сергей Леухин журналистлар очен брифинг vткәрде. Язгы чакырылыш кампаниясе йомгакларына һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләv, республикабызда «Коз – 2025» чакырылыш кампаниясен оештыру һәм уздыру мәсьәләләренә багышланган иде.

Сергей Леухин хәбәр иткәнчә, язгы чакырылыш барышында Россия Федерациясе Кораллы кочләрен һәм башка федераль органнарнын хәрби формированиеләрен сан һәм сыйфат кvрсәткечләре буенча комплектлауга Үзәк хәрби округ штабы тарафыннан билгеләнгән йокләмә тулысынча vтәлгән.
- Язгы чакырылыш кампаниясе барышында Кораллы Кочләргә, башка гаскәрләргә һәм хәрби формированиеләргә хәрби хезмәт vтv очен Мордовия Республикасыннан 1000нән артык кеше жибәрелде, шул исәптән «Армиянен vзәк спорт клубы» спорт ротасына һәм фәнни роталарга 11 егет юлланды. Фәнни роталарга сайлап алу югары уку йортларында һәм хәрби комиссариатларда хәрби хезмәткә яраклы һәм фәнни эшкә һәвәс талантлы хәрби хезмәткә чакырылучылар арасыннан шәхсән узды. Әмма минем санап киткәннәрдән тыш тагын бер фактор бар: фәнни рота операторы булу очен профиль буенча югары белем, Оборона министрлыгы мәнфәгатьләрендә уздырыла торган фәнни тикшеренvләрнен тиешле юнәлеше кирәк», - дип билгеләде РМ хәрби комиссары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы.
Республикадан хәрби хезмәткә китvчеләрнен барысы да кондәлек кием формасы, шулай ук несессерлар (аерым сумка), банк һәм персональ электрон карталар белән тәэмин ителде.
Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, 1 октябрьдән гражданнарны козге хәрби хезмәткә чакыру башланды. Ул 2025 елнын 1 октябреннән 31 декабренә кадәр

планлаштырылган тәртиптә уздырылачак.
 - Хәрби хезмәткә чакыру срогы үзгәрмәячәк һәм 12 ай тәшкил итәчәк, ә хәрби хезмәткә чакырылучыларны Мордовия Республикасы җыю пунктыннан җибәрү 2025 елнын 15 октябреннән планлаштырылган. Хәрби хезмәткә чакырылучыларнын барысы да хәрби хезмәтне үтү очен берләшмәләрнен һәм хәрби частьләрнен даими дислокация пунктларына Россия Федерациясе территориясенә генә җибәреләчәк. Шунысын да билгеләп үтәсем килә, чакырылыш буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр махсус хәрби операция бурычларын үтәүдә катнашу очен җәлеп ителмәячәк», - дип аерым ассызыклады Сергей Леухин.
Хәрби хезмәткә чакырылучыларнын кимендә очтән бере укыту берләш-мәләренә һәм хәрби частьләргә эләгәчәк, анда заманча хәрби техника үзләштереләчәк һәм хәрби-учет белгечлеге алачак, шунын нигезендә укуны тәмамлагач гаскәрләргә җибәреләчәк. Шул ук вакытта без фәнни-гамәли бурычларны хәл итү очен билгеләнгән фәнни роталарны формалаштыру практикасын дәвам итәчәкбез, - диде РМ хәрби комиссары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы. - Производствога алдынгы идеяләрне һәм алга киткән технологияләрне кертүче фәнни-житештерү бүлекчәләрен, шулай ук ин перспективалы спортчыларны әзерләү очен тиешле шартлар тудырылган спорт роталарын туплауны игътибарсыз калдырмыйбыз.
Күрсәтелгән бүлекчәләрне комплектлау очен кандидатларга куела торган таләпләр һәм хәрби хезмәткә чакырылу һәм хәрби хезмәт узу мәсьәләләре буенча мәгълүмат белән хәрби хезмәткә чакырылучылар һәм аларнын ата-аналары Оборона министрлыгынын рәсми интернет-порталында таныша ала. Козге чакырылыш кампаниясе «Хәрби исәпкә алунын бердәм реестры» дәүләт мәгълүмат системасын кулланып үткәреләчәк.
Сергей Леухин кон тәртибендәге яналыклар турында да сойләде:
- Кон тәртибен житкерү механизмы үзгәртелде. Гражданнарга кәгазь повесткалар белән беррәттән электрон повесткалар да җибәреләчәк. Повестканы җибәрү турындагы мәгълүмат җибәрелгән (тапшырылган) повесткаларнын һәркем очен момкин булган реестрына кертелә һәм повесткалар реестрында урнаштырылганнан сон жиде кон узгач гражданга тапшырылган дип санала. Тапшырылган повестка буенча житди сәбәпсез килмәгән очракта, 20 календарь кон узгач, гражданга «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль закон нигезендә, анын килүен тәэмин итүгә юнәлдерелгән вакытлыча чикләү чаралары кулланыла. Әлеге чикләү чаралары гражданиннан хәрби комиссариатка килү факты буенча ук алына. Электрон повестка җибәрү, вакытлыча чикләү чараларын куллану һәм гамәлдән чыгару турында хәбәрнамәләр гражданинга дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталындагы шәхси кабинетка җибәрелә.
Гражданнар хәрби исәп реестрындагы үзләре турында, шул исәптән юнәлдерелгән кон тәртибе һәм вакытлыча чикләү чаралары турында мәгълүмат белән таныша ала. Моны «реестрповесток.рф» адресы буенча повесткалар Реестрынын шәхси кабинетында формалаштырыла торган тиешле выписканы алып эшләп була.
- Тагын бер үзенчәлек шунда ки, хәрби хезмәткә чакыру турындагы карар кабул ителгәннән сон бер ел дәвамында гамәлдә (действительно). Ягъни, әгәр хәрби хезмәткә чакырылган гражданин нинди дә булса сәбәпләр аркасында аны агымдагы чакырылышта узу очен җибәрелмәгән булса, ул аны узу очен киләсе чакырылыш кампаниясен уздыру чорында җибәрелә»,- дип ачыклык кертте РМ хәрби комиссары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы.
Беренче октябрьдән хәрби комиссариатта чакырылыш кампаниясен үткәрү мәсьәләләре

буенча халыкка мәгълvмат бирv очен «Кайнар линия» эше оештырылган (телефон: (8342) 38-55-14). Анда белгечләр гражданнарны хәрби хезмәткә чакыру белән бәйле мәсьәләләр буенча анлатмалар бирәчәкләр. Шулай ук e-mordovia сайтында «Хәрби комиссариатлар» бvлеге эшли; анда чакырылыш мәсьәләләре буенча актуаль белешмә мәгълvмат урнаштырылган һәм даими янартыла.
- Билгеләп vтәм: чакырылыш буенча хәрби хезмәтнен билгеләнгән срокларын vтәгән барлык хәрби хезмәткәрләр vз вакытында демобилизацияләнәчәк һәм яшәv урыннарына жибәреләчәк, - дип ышандырды Сергей Леухин.

**Наилә НАСЫРОВА**